ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ФӘННӘР АКАДЕМИЯСЕ
Г. ИБРАҺИМОВ исемендәге
ТЕЛ, ӘДӘБИЯТ ҺӘМ СӘНГАТЬ ИНСТИТУТЫ

**В.М. Усманов**

# БАШКОРТСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ТАТАР ЭПИГРАФИК ҺӘЙКӘЛЛӘРЕ

## Бүздәк районы Шланлыкүл авылы

Казан
2021

**УДК 930.271**
**ББК 63.2**
**У 74**

*Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең*
*Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты*
*Гыйльми советы карары нигезендә нәшер ителә*

**Фәнни редактор**
филология фәннәре кандидаты *И.Г. Гомәров*

**Рецензент**
филология фәннәре кандидаты, доцент *А.М. Ахунов*

**Усманов В.М.**
У 74 Башкортстан Республикасы татар эпиграфик һәйкәлләре: Бүздәк районы Шланлыкүл авылы. – Казан: ТӘһСИ, 2021. – 32 б.
ISBN 978-5-93091-358-3

Җыентыкта Башкортстан Республикасының Бүздәк районына караган Шланлыкүл авылы зиратында сакланып калган һәм гарәп хәрефләре белән татар телендә язылган дистәдән артык ташъязма истәлек турында мәгълүмат туплап бирелә.

Хезмәт Идел-Урал төбәге тарихын һәм мәдәниятен өйрәнүче галимнәр, гомумән татар халкының тарихи үткәне белән кызыксынучы укучылар өчен тәкъдим ителә.

УДК 930.271
ББК 63.2

**ISBN 978-5-93091-358-3**

© Усманов В.М., 2021;
© Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият
һәм сәнгать институты, 2021

## БАШКОРТСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ БҮЗДӘК РАЙОНЫ ШЛАНЛЫКҮЛ АВЫЛЫ ТАШЪЯЗМА ИСТӘЛЕКЛӘРЕ

Көньяк Урал территориясендә сакланып калган борынгы эпиграфик һәйкәлләр – татар халкының тарихи үткәненә мөнәсәбәтле чыганакларның берсе. Мәгълүм ки, бу төбәк элек-электән Болгар, Дәште Кыпчак, Нугай Урдасы татарларының биләмәләре саналган. XVIII гасырның беренче яртысында (1708–1728 һәм 1731–1734 елларда) әлеге җирләр, Уфа өязенә кереп, Казан губернасының бер административ-территориаль өлешен тәшкил иткән[1].

Башкортстан Республикасының Бүздәк районы Шланлыкүл авылы җирлегендәге гарәп хәрефләре белән татар телендә язылган ташъязмаларны да әлеге тарихи чыганаклар рәтендә карарга мөмкин. Кызганыч ки, бу ядкярләрнең бүгенге көнгәчә тәфсилле тикшерү объектына әверелеп, фәнни әйләнешкә тәкъдим ителгәннәре юк. Әлеге фактларны искә алып, бу җыентыкта Шланлыкүл авылы зиратында сакланган һәм тарихи, фәнни, сәнгати яктан игътибарга лаек 15 берәмлек эпиграфик һәйкәл хакында мәгълүматлар туплап бирелде: ташларның фотолары, кайберләренең график сурәтләре урнаштырылды, гарәп графикасындагы текстлары гамәлдәге язуга күчерелеп, шәрех-аңлатмалар белән тәкъдим ителде.

Хронологик яктан караганда, бу ташъязмалар XIX гасырга карый. Даталары төгәл укылганнары арасында иң әүвәлгесе – 1832,

[1] Регионы компактного проживания татар в Российской Федерации: справочник / отв. ред.: М. Айнутдинова, Б.Л. Хамидуллин. Казань: ОП «Институт татарской энциклопедии и регионоведения АН РТ», 2016. С. 137.

соңгысы 1924 елга карый. Шланлыкүл авылы зиратында бик борынгы чорларга, әйтик, Алтын Урда яисә Нугай Урдасы дәверләренә караган ташъязмалар юк. Ташларның сакланыш дәрәҗәсе дә төрле: араларында яхшы сакланганнары да, җимерелгән һәм бик таушалганнары да бар. Шунысын да билгеләп үтәргә кирәк: дингә каршы көрәш заманаларында биредәге ядкярләрне махсус җимерү яисә аларны төзелеш материалы рәвешендә файдалану кебек ямьсез күренешләр булмаган, фәкать табигатьтәге һава шартлары гына кайбер ташъязма истәлекләргә зыян салган.

Шланлыкүл эпиграфик һәйкәлләрендә аерым шәхесләргә бәйле, яисә татар морзаларының үзара нәсел бәйләнешләренә нисбәтле мөһим тарихи мәгълүматлар теркәлгән очраклар да бар. Әйтик, күренекле мәгърифәтче, үзе дә беренчеләрдән булып Болгар эпиграфик ядкярләрен тикшергән галим Хөсәен Фәезхановның олы кызы Бибигайшә Шланлыкүл авылында җирләнгән. Ташъязмадан күренгәнчә, Бибигайшә Шаһхәйдәр Сыртлановта кияүдә булган, 1887 елда, 30 яшенә җитеп, бакыйлыкка күчкән. Галим Миркасыйм Госманов фикеренчә, Бибигайшәнең бер улы – Галиәсгар Сыртланов Петербургта адвокат булып эшләгән һәм III Дәүләт Думасында әгъза булып торган; икенче бер улы – Равил Сыртланов полковник дәрәҗәсендә Беренче бөтендөнья сугышында катнашкан һәм канкойгыч бәрелешләрнең берсендә һәлак булган[1], Шланлыкүл зиратына алып кайтып җирләнгән. Шулай ук, әлеге нәсел кешеләренә куелган ташъязмалардан, морза Сыртлановларның Азнакай төбәгендә гомер кичергән морзалар Ногайбәковлар белән туганлык мөнәсәбәтләрендә торганлыклары хакында да белергә мөмкин.

Шланлыкүл ташъязмалары өчен чимал рәвешендә читтән китерелгән кирәч таш (известь таш) һәм урындагы комташ кулланылган. Комташның табигый үзенчәлекләре тиз югала, еллар үтү белән ул йомшара, ватыла, шуңа биредәге ядкярләрнең бер өлешенең язулары танымаслык хәлгә килгән. Югарыда искә алынган Бибигайшәгә куелган истәлек тә инде бүген җимерелеп юкка чыгу алдында тора.

---

[1] *Усманов М.* Заветная мечта Хусаина Фаизханова. Повесть о жизни и деятельности. Казань: Татар. кн. изд-во, 1980. С. 212.

Шланлыкүл ташъязмаларының авторлары безгә мәгълүм түгел. Башка төбәкләрдәге кебек, бу авылда да таш уючы үз осталары булгандыр. Шулай да, бу истәлекләрнең төп өлеше чит төбәк хаттатлары тарафыннан язылган дию дөресрәк булыр. Ташларның палеографик үзенчәлекләре дә шундый нәтиҗә ясарга нигез бирә. Мәсәлән, биредәге 1832–1841 еллар аралыгында куелган ядкярләргә охшаш ташъязмаларны Татарстанның Азнакай, Актаныш, Сарман, Мөслим районнарында еш очратырга мөмкин. Хөсәен Фәезханов кызы Бибигайшә, аның улы Равил Сыртлановка куелган истәлекләрнең исә Уфа яки Дәүләкән хаттатлары тарафыннан эшләнгән булуы ихтимал. Шунысы да мөһим: биредә Оренбург, Троицк, Стәрлебаш, шул исәптән Казан каллиграфларының эшләре күренми. Гомумән, бу төбәктә таш карьерларының булмавы сәбәпле, таш язу сәнгате киң үсеш алмаган. Палеографик яктан күзәтүләр шуны күрсәтә: мондагы язу традицияләре, гадирәк булсалар да, яңа алымнар һәм индивидуаль язу үзенчәлекләре белән аерылып, үзгәрешләр кичергән. Язу үрнәкләрендә, мәсәлән, Казандагыча нәстәгъликъ яисә рокъга кебек язу өслүбләре күзәтелми. Композицияләрнең күбесендә сөлескә охшаш нәсех язуы өстенлек итә.

Җыентык татар тарихы белән кызыксынучылар күңеленә хуш килер дигән өметтә калабыз.

**_Венер Усманов,_**
_Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе_
_Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының_
_Язма һәм музыкаль мирас үзәге фәнни хезмәткәре_



1=A

## ТАШЪЯЗМАЛАР

### 1. Сыртлан улы Ишбулды каберенә куелган таш. 1832 ел

Алгы ягында (калку язулы):

| | |
|---|---|
| تاريخ روميه | *тарих румия илән* |
| ١٨٣٢ نچى يلده | *1832 нче йылда* |
| اشبولدى صرطلان اوعلى | *Ишбулды Сыртлан углы* |
| يتمش بش ياشنده | *йетмеш биш йәшендә* |
| دارالفنادين بقايه نقل قلدى | *дарелфәнадин бәкайә нәкыль кылды*[1] |

Үлчәмнәре: 10×45×110 см.

### 2. Бикморза кызы Хәдичә каберенә куелган таш

Алгы ягында (калку һәм уйма язулы):

| | |
|---|---|
| ١٨... نچى | *18...*[2] *нче* |
| تاريخ روميه ايلان ا | *тарих румия илән* |
| يلده حديچه بيک مرظا قزى | *йылда Хәдичә Бикморза кызы* |
| قرق بش يا شنده | *кырык биш йәшендә* |
| دارالفنادين بقايه نقل قلدى | *дарелфәнадин бәкайә нәкыль кылды* |

[1] *Дарелфәнадин бәкайә нәкыль кылды* – фани дөньядан бакый дөньяга күчте.
[2] 1837 (?).



1=A



2=A

| | |
|---|---|
| يلنا ضيرا… | …[1] |
| … | … |
| يَا وقفًا بقبرى متفكّرًا بامرى | *йа вакыйфән би кабри мөтәфәккирән би-әмри* |
| بالامسى كنت مثلك غدى تصير مثلى | *бил-әмси күнтү мисликә гадән тәсайир мисли*[2] |

Ядкяр бурташ – кызгылт-көрән төстәге керәч (известьняк) таштан ясалган, ташъязма әкренләп җимерелә бара.

Үлчәмнәре: 10×40×115 см.

---

[1] Алтынчы һәм җиденче юлларда дога язылган.

[2] *Йа вакыйфән би-кабри, мөтәфәккирән би әмри; бил-әмси күнтү мисликә, гадән тәсайир мисли* – Әй каберем янына килеп басучы, минем хәлне фикерлә; бүген шул хәлеңдә булсаң, иртәгә минем кебек булырсың.



2=A

## 3. Кормәкәй кызы Мирвафа каберенә куелган таш. 1837 ел

Алгы ягында (калку язулы):

| | |
|---|---|
| اشهد ان لا اله الاالله و اشهد | *әшһәдүән-лә иләһә иллә Аллаһу вә әшһәдү* |
| ان محمدا عبده و رسوله | *әннә Мүхәммәдән габдүһү вә расүлүһү*[1] |
| ١٨٣٧ نچی یلده | *1837 нче елда* |
| میروفا قر مکای قزی ٣٠ | *Мирвафа Кормәкәй*[2] *кызы 30* |
| بش یاشنده | *биш йәшендә* |
| دارالفنادین بقایه نقل قلدی | *дарелфәнадин бәкайә нәкыль кылды*[3] |

Үлчәмнәре: 10×48×100 см.



3=А

[1] Кәлимәи шәһадәт: бер Аллаһтан башка илаһи зат юклыгын һәм Мөхәммәд аның илчесе булуын таныйм.

[2] Бөгелмә өязе Урсай авылы зиратында Кормәкәй Нугайбәк угылының (1820 ел) кабер ташы бар. (Кара: *Әхмәтҗанов М.И.* Меңеллык татар нәселе: Татар шәҗәрәләре һәм этник тарихыбызга бер караш. Казан: Мәгариф, 2001. Б. 32.

[3] *Дарелфәнадин бәкайә нәкыль кылды* – фани дөньядан мәңгелек дөньяга күчте.




3=A

**4. Шаһ-Гярдән кызы Хөснезияд каберенә куелган таш. 1838 ел**

Алгы ягында (калку язулы):

| | |
|---|---|
| تاریخ ۱۸۳۸ نچی | *тарих 1838 нче* |
| یلده بی بی حسنی زیاد شاهی کردن | *йылда Биби Хөснезияд Шаһ-Гярдән* |
| قزی | *кызы* |
| ۴یاشنده دار الفنادین بقایه نقل | *4 йәшендә дарелфәнадин бәкайә нәкыль* |
| قلدی رحمة الله رحمة | *кылды, рәхмәтуллаһи рәхмәтән* |
| واسعة … | *васигатән, …[1]* |
| فان … | … |

Ядкяр бурташтан[2] ясалган, ташъязма җимерелеп юкка чыга бара. Үлчәмнәре: 10×43–48×95 см.



4=А

[1] Текстның азагы дога белән тәмамлана.
[2] Бурташ – кызгылт-көрән төстәге керәч таш (известьняк).




4=A

**5. Шаһ-Гярдән улы Шаһхәйдәр каберенә куелган таш. 1841 ел**

Алгы ягында (калку язулы):

| | |
|---|---|
| تاريخ روميه ايلان | *тарих румия илән* |
| ١٨٤١ نچى يلده شه حيدر | *1841 нче йылда Шаһхәйдәр* |
| شه كاردن اوعلى دار | *Шаһ-Гярдән углы даре-* |
| الفنادين بقايه نقل قلدى | *лфәнәдин бәкайә нәкыль кылды* |
| … | ...[1] |

Ядкяр бурташтан ясалган, җимерелеп юкка чыгып бара.



5=А

[1] Ташъязманың ахыры җуелган.



5=A

**6. Кемгә куелганы мәгълүм булмаган таш.**
**1850 ел**

Алгы ягында (уйма язулы):

| | |
|---|---|
| اعوذ بالله | *әгузе билләһи* |
| من الشيطان الرجيم | *мин әш-шәйтан ир-раҗим* |
| بسم الله الرحمن الرحيم | *бисмиллаһир-Рахманир-Рахим*[1] |
| لا اله الا الله محمد رسول الله | *лә иләһә иллә Аллаһу Мөхәммәд рәсүлуллаһ*[2] |
| فا … | *Фа…*[3] |
| ٧ … | *7 [йәшендә дарелфәнадин дарелбәкайә]* |
| نقل قلدى انا لله وانا الله راجعون | *нәкыль кылды, иннә лилләһи вә иннә иләйһи раҗигун*[4] |
| تاريخ روميه ايلان ١٨٥٠ | *тарих румия илән 1850* |
| نچى يلده ٥ | *нче йылда 5* |
| يَا وقفًا بقبرى | *йә вакыйфән би-кабри* |
| متفكّرا بامرى | *мөтәфәккирән би-әмри* |
| بالامسى كنت مثلك | *бил-әмси күнтү мисликә* |
| غدا تصير مثلى | *гадән тәсайир мисли*[5] |

Ядкяр ком ташыннан ясалган, авторы мәгълүм түгел. Эпиграфик һәйкәл җимерелеп-җуелып юкка чыгып бара.

Үлчәмнәре: 9×40×120 см.

---

[1] Таш белән куылган шайтаннан качып, Аллаһка сыгынам.

[2] Аллаһтан башка илаһи зат юк, Мөхәммәд – Аллаһның илчесе.

[3] Мәрхүм(ә)нең исем-шәрифләре язылган булган.

[4] *Инна лилләһи вә иләйһи раҗигун* – (Коръән, «Бәкарә» сүрәсе, 155 нче аять) – Аллаһ тарафыннан яратылганбыз һәм аның хозурына кайтабыз.

[5] *Йа вакыйфән би-кабри, мөтәфәккирән би-әмри, бил-әмси күнтү мисликә, гадән тәсайир мисли* – Әй, каберем янына туктаган, Аллаһының әмере турында уйлаган [кеше]! Кичә мин синең кебек идем, иртәгә син дә минем кебек булырсың.



6=А

7=А



**7. Шаһмөхәммәд каберенә куелган таш.**
**1851 ел**

Алгы ягында (уйма язулы):

| | |
|---|---|
| اعوذ بالله | *әгузе билләһи* |
| من الشيطان الرجيم | *мин әш-шәйтан ир-раҗим*[1] |
| بسم الله الرحمن الرحيم | *бисмиллаһир-Рахманир-Рахим* |
| لا اله الا الله محمد رسول الله | *лә иләһә иллә Аллаһу Мөхәммәд рәсүлуллаһ*[2] |
| شه محمد بن شه … | *Шаһ-Мөхәммәд бине Шаһ…* |
| یاشنده دار الفنادين بقايه نقل | *йәшендә дарелфәнадин бәкайә нәкыль* |

[1] *Әгузе билләһи мин әш-шәйтан ир-раҗим* – таш белән куылган шайтаннан качып, Аллаһка сыгынам.

[2] *Лә иләһә иллә Аллаһ Мөхәммәд рәсүлуллаһ* – Аллаһтан башка илаһи зат юк, Мөхәммәд Аллаһның илчесе.

| | |
|---|---|
| قلدی انا لله وانا الله راجعون | *кылды, иннә лилләhи вә иннә иләйhи раҗигун*[1], |
| تاریخ رومیه ایلان ۱۸۵۱ | *тарих румия илән 1851 нче йылда* |
| یٓا وقفًا بقبری | *йә вакыйфән би-кабри* |
| متفكّرا بامری | *мөтәфәккирән би-әмри* |
| بالامسی كنت مثلك | *бил-әмси күнтү мисликә* |
| غدا تصیر مثلی | *гадән тәсайир мисли*[2] |

Ядкяр ком ташыннан ясалган, авторы мәгълүм түгел. Ташъязма җуелып юкка чыгып бара.

Үлчәмнәре: 10×40×120 см.

**8. Кемгә һәм кайчан куелганы мәгълүм булмаган таш**

Алгы ягында (уйма язулы):

| | |
|---|---|
| اعوذ بالله | *әгузе билләһи* |
| من الشیطان الرجیم | *мин әш-шәйтан ир-раҗим* |
| بسم الله الرحمن الرحیم | *бисмиллаhир-Рахманир-Рахим* |
| لا اله الا الله محمد رسول الله | *лә иләһә иллә Аллаһи Мөхәммәд рәсүлуллаһ* |
| شه … | *Шаh …* |
| یاشنده دار الفنادین بقایه نقل | *… йәшендә дарелфәнадин бәкайә нәкыль* |
| قلدی انا لله وانا الله راجعون | *кылды, иннә лилләhи вә иннә иләйhи раҗигун,* |
| تاریخ رومیه ایلان …۱۸ نچی یلده | *тарих румия илән 18… нче йылда* |

Ядкяр ком ташыннан ясалган, авторы мәгълүм түгел. Эпиграфик һәйкәл җимерелеп-җуелып юкка чыгып бара.

Үлчәмнәре: 12×45×120 см.

---

[1] *Иннә лилләhи вә иннә иләйhи раҗигун* – Коръән, «Бәкарә» сүрәсе, 155 нче аять) – Аллаһ тарафыннан яратылганбыз һәм аның хозурына кайтабыз.

[2] *Йа вакыйфән би-кабри, мөтәфәккирән би-әмри, бил-әмси күнтү мисликә, гадән тәсайир мисли* – Әй, каберем янына туктаган, Аллаһының әмере турында уйлаган [кеше]! Кичә мин синең кебек идем, иртәгә син дә минем кебек булырсың.



8=А

9=А



**9. Габдеррахман кызы Биби Гафифә каберенә куелган таш. 1881 ел**

Алгы ягында (уйма язулы):

| | |
|---|---|
| لا اله الا الله | *лә иләһә иллә Аллаһу* |
| محمد رسول الله | *Мөхәммәд рәсүлуллаһ*[1] |
| الله تعالى كل نفس ذائقة | *Аллаһы Тәгалә, көллү нәфсин заикат-* |
| الموة المغفور المدفون مرحومه | *-ел-мәүт*[2] *әл-мәгъфүр әл-мәдфүн мәрхүмә* |
| بى بى عففه بنت عبد الرحمن | *Биби Гафифә бинте Габдеррахман* |
| قرعلى ١٨٨١ نچى يلده | *Каргалый*[3] *1881 нче йылда* |
| … | … |

Ядкяр ком ташыннан ясалган, табигый рәвештә җимерелеп юкка чыгып бара.

Үлчәмнәре: 10×33–60×80 см.

---

[1] *Лә иләһә иллә Аллаһу Мөхәммәд рәсүлуллаһ* – Аллаһтан башка илаһи зат юк, Мөхәммәд Аллаһның илчесе.

[2] *Көллү нәфсин заикател-мәүт* – Һәрбер җан үлем тәмен татып караячак.

[3] Благовар төбәгендәге авыл.

## 10. Сыртланов Шаһхәйдәр улы Ибраһим каберенә куелган таш. 1883 ел

Алгы ягында (уйма язулы):

| | |
|---|---|
| يتمنا بزكره الاعلى | ... |
| ١٨٨٣ نچى سنه ده اوكتبر | *1883 нче сәнәдә октябрь-* |
| ننک ١٥ نچى كوننده ٣ ياشنده | *нең 15 нче көнендә 3 яшендә* |
| ابرهيم بن شاه حيدر | *Ибраһим бине Шаһхәйдәр* |
| صرطلانف دار الفنادين بقايه نقل قلدى... | *Сыртланов дарелфәнадин бәкайә нәкыль кылды ...*[1] |

Үлчәмнәре: 7×37×50 см.



10=А

[1] Ташъязманың ахыры җир белән капланган.



10=A




11=A

## 11. Мулла Хөсәен Фәйзханов кызы Биби Гайшә каберенә куелган таш. 1887 ел

Алгы ягында (калку һәм уйма язулы):

| | |
|---|---|
| بسم الله الرحمن الرحيم | *бисмиллаһир-Рахманир-Рахим*[1] |
| ١٨٨٧ نچی سنه ... یولدزننک | *1887 нче сәнә... йолдызының* |
| ١٩ نچی کوننده | *19 нчы көнендә* |
| بیبی عشه ملا حسین قزی | *Биби Гайшә мулла Хөсәен кызы*[2] |
| شاه حیدرصرطلانف زوجه سی | *Шаһ-Хәйдәр Сыртланов зәүҗәсе* |
| ٣٠ سنه عمر کچروب دارالفنادین | *30 сәнә гомер кичереб дарелфәнадин* |
| دارالبقایه کوچب | *дарелбәкайә күчеб* |
| قردش و دوست اشنه و غیر اهل | *кардәш вә дуст әшнә вә гайре әһле* |
| اسلام ... | *ислам* |
| اولوب جمله لاری انا لله و | *улыб җөмләләре иннә лилләһи вә* |
| انا الله راجعون اوقوب | *иннә иләйһи раҗигун укыб* |
| الله تعالی کناه لرون عفو ایدوب الوع | *Аллаһы Тәгалә гөнаһларын гафу* |
| رحمتلرینه | *идүб олугъ рәхмәтләренә* |
| ایرشدروب روح شریفلاری منکو | *ирештереб рух шәрифләре мәнге* |
| شادلق ده | *шадлыкда* |
| قیلوب جنات عالیه لاری اله | *кылыб җәннәт галияләре илә* |
| حرمتلکای ایدی | *хөрмәтләкәй иде* |

Ядкяр ком ташыннан ясалган, авторы мәгълүм түгел. Эпиграфик һәйкәл җимерелеп юкка чыгу халәтендә.

Үлчәмнәре: 15×60×120 см.

---

[1] *Бисмиллаһир ир-рахман ир-рахим* – рәхимле, шәфкатьле Аллаһның исеме белән.

[2] «Старшая, т.е. Биби-Айша, была замужем за Хайдаром Сыртлановым; один из ее сыновей, Галиасгар Сыртланов, был адвокатом в Петербурге и состоял членом III Государственной Думы; другой сын, армейский офицер Равил Сыртланов, погиб летом 1916 г. на фронте» *(Усманов Миркасым.* Заветная мечта Хусаина Фаизханова. Повесть о жизни и деятельности. Татар. кн. изд-во, 1980. С. 212).




11=A

## 12. Зәйнуллин улы Ардуан каберенә куелган таш. 1906 ел

Алгы ягында (калку һәм уйма язулы):

| | |
|---|---|
| كفى بالموت وعظا | *кәфә бил-мәүти вагыйзән*[1] |
| تاريخ … | *тарих [1906] …*[2] |
| ذى الحجه ننك … نچى كوننده … | *зөлхиҗҗәнең … нче көнендә …*[3] |
| اردوان اوعلى زينوللين | *Ардуан углы Зәйнуллин* |
| … سنه عمر كچروب دارفنادين داربقايه | *… сәнә гомер кичереб дарелфәнадин дарелбәкайә* |
| … قارب سبيه واحلاء | ... |
| … | ... |

Ядкяр бурташтан ясалган, ватылып-җимерелеп юкка чыгып бара, авторы мәгълүм түгел.

Үлчәмнәре: 9×35–40×75 см.



12=А

[1] *Кәфә бил-мәүти вагыйзән* – Үлем – зирәк укытучы.
[2] 1906 (?) нчы сәнәдә.
[3] Кави (?).

## 13. Сыртланов Арсланбәккә бәйле таш. 1907 ел

Алгы ягында (уйма язулы):

| | |
|---|---|
| ١٩٠٧ يلده مارت ننک ۶ نچی کوننده | *1907 йылда мартның 6 нчы көнендә* |
| وفات بولدی ارصلاننک … | *вафат булды Арсланның*[1] … |
| شرفی کمال… | *Шәрфикәмал…*[2] |



13=А

---

[1] Арсланбәк Шаһигәрдән углы (?).
[2] Шәрфикәмал (7) …

**14. Шаһхәйдәр улы Сыртланов Равил каберенә куелган таш. 1916 ел**



14=A=a

Алгы ягында (калку язулы):

| | |
|---|---|
| کفی بالموت وعظا | *кәфә бил-мәүти вагыйзән*[1] |
| تاریخ رومیه ایله ۱۹۱۶ نچی یلده | *тарих румия илә 1916 нчы йылда* |
| ایيولنڭ ۲ نچی کوننده پالکا | *июльнең 2 нче көнендә полко-* |
| وای کاماندیر پالکاونیك | *вой командир полковник* |
| راویل شاه حیدر اوغلی صرطلا | *Равил Шаһхәйдәр углы Сыртла-* |
| نف ۳۸ یاشنده زور صوغشده | *нов 38 йәшендә зур сугышта* |
| گیرمان فرونتنده برانویچ شهری | *герман фронтында Баранович шәһәре* |
| یاننده دشمان طرفندن ملطق | *йанында дошман тарафыннан мылтык* |
| … | ...[2] |

Ядкяр ком ташыннан ясалган, авторы мәгълүм түгел.
Үлчәмнәре: 16×60×150 см.



14=А=б

[1] *Кәфә бил-мәүти вагыйзән* – Үлем – зирәк укытучы.
[2] Ташъязманың ахыры җир белән капланган.




14=A

## 15. Мулла Тәүхидеддин улы Фәхеррази каберенә куелган таш. 1916 ел

Алгы ягында (уйма язулы):

سنهء ۱۹۱۶ نچی مای ۱۷نده فحررازی ملا توحید الدین اوعلی صرطلانف ۲۹ یل عمر
سروب دارالفنادان دارالبقایه رحلت قلدی انا لله وانا الله راجعون ...

*сәнәи 1916 нчы май 17 ндә Фәхеррази мулла Тәүхидеддин углы*
*Сыртланов 29 ел гомер сөреб бу дарелфәнадән дарелбәкайә*
*рихләт кылды иннә лилләhи вә иннә иләйhи раҗигун*[1]...

Үлчәмнәре: 8×35×70 см.



15=А

[1] Аллаhы тарафыннан яратылганбыз hәм аның хозурына кайтабыз.



سنه ۱۹۱۶ نچی
مای ۱۷ نده
محررازی ملا
توحید الدین اوغ
صرطلانف ۲۹ یل
عمر سرف بودار الفنا
دان دار البقا به رحلت
قیلدی انا لله وانا الیه
راجعون


15=A

**Усманов Венер Мударрисович**

**ТАТАРСКИЕ
ЭПИГРАФИЧЕСКИЕ ПАМЯТНИКИ
РЕСПУБЛИКИ БАШКОРТОСТАН**

**Буздякский район
Деревня Шланлыкулево**

(на татарском языке)

Корректоры: *Е.Ф. Лукьянченко, Л.Г. Шарифуллина*
Компьютерная верстка *Н.Т. Абдуллиной*
Дизайн обложки *А.Б. Шляпкина*

Подписано в печать 20.01.2021.
Формат 60×84 1/16. Гарнитура «Таймс». Бумага офсетная.
Усл.-печ. л. 1,9. Уч-изд. л. 1,6. Тираж 300 экз. Заказ

Оригинал-макет подготовлен в Институте языка, литературы
и искусства им. Г. Ибрагимова АН РТ
420111, Казань, ул. К. Маркса, 12

Издательство Академии наук Республики Татарстан
420111, Казань, ул. Баумана, 20